КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 29 сентябрь г.Казань № 927

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләренә хезмәт күрсәтә торган транспорт чараларының норматив саны, үткән юлы һәм аларны агымдагы карап тоту чыгымнары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер актлары үз көчен югалткан дип санау турында» 2018 ел, 1 декабрь, 1073 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 7 март, 165 нче; 2019 ел, 17 май, 402 нче; 2019 ел, 13 июль, 572 нче; 2019 ел, 2 ноябрь, 1006 нчы; 2020 ел, 18 февраль, 123 нче; 2020 ел, 27 апрель, 331 нче; 2020 ел, 9 июнь, 477 нче; 2020 ел, 24 июль, 622 нче; 2020 ел, 5 сентябрь, 790 нчы; 2020 ел, 21 ноябрь, 1042 нче; 2020 ел, 30 декабрь, 1230 нчы; 2021 ел, 14 май, 334 нче; 2021 ел, 30 июнь, 520 нче; 2021 ел, 17 август, 739 нчы; 2021 ел, 1 сентябрь, 803 нче

карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның бишенче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Әгәр дә транспорт чаралары арендага машина йөртүче белән бергә алынса, машина йөртүче белән такси хезмәте күрсәтүләре кулланыла йә, куллану өчен машина йөртүче хезмәте күрсәтүләре белән бергә башка ысул кабул ителсә, аларны карап тоту чыгымнарын исәпләү өчен Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләргә хезмәт күрсәтүче транспорт чараларын (ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен транспорт чараларыннан башка) агымдагы карап тотуга норматив еллык чыгымнар кулланыла;»;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы һәм аның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында:

1 пунктның 4 графасында «5» санын «6» санына алмаштырырга;

«Барлыгы» юлында «12» саннарын «13» саннарына алмаштырырга.

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасы ведомстволары һәм аларның ведомство буйсынуындагы учреждениеләре өчен транспорт чаралары белән тәэмин ителеш нормативларында (иң чик санында) һәм транспорт чараларының норматив буенча үткән юлында түбәндәге юллар үз көчен югалткан дип танырга:

| Татарстан Республикасының Социаль-икътисадый мониторинг комитеты | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Ведомство аппараты | рәис | 1 | җиңел автомобиль | 32 805 | 135». |

Татарстан Республикасы
Премьер-министр А.В.Песошин